КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

08.06.2026 №94-п

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында дәүләт граждан хезмәтенең коррупциячел хәтәрләргә бәйле, дәүләт граждан хезмәткәрләре белгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай һәм иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ТРЗ номерлы Федераль законны, «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге 636-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын, «Дәүләт граждан хезмәтенең коррупциячел хәтәрләргә бәйле, дәүләт граждан хезмәткәрләре билгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай һәм иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге 701-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын, «Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъва итә торган гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшыруы турында” 2009 елның 30

декабрендәге 702-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын үтәү максатыннан боерык бирәм:

1. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында дәүләт граждан хезмәтенең коррупциячел хәтәрләргә бәйле, дәүләт граждан хезмәткәрләре биләгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай һәм иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфалары исемлеген расларга.

2. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында дәүләт граждан хезмәтенең керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр һәм хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле коррупциячел хәтәрләргә бәйле вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 16 декабрендәге 45-п номерлы «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ф. Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы җитәкчесенең

номерлы боерыгы белән
расланды

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында дәүләт граждан хезмәтенең керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр һәм хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле коррупциячел хәтәрләргә бәйле вазыйфалары исемлеге

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары баш төркеменең «Житәкчеләр» категориясе:
җитәкченең беренче урынбасары;
җитәкче урынбасары.